СОВЕТ ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ш.Маннура, д.72а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ш.Маннур ур., 72а нче йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-82; e-mail:Olu.Mam@tatar.ru, www: mamadysh.tatarstan.ru

Карар
"20" ноябрь, 2018ел.

Решение
№4-37

## 2018 елның 18 ноябрендә үткәрелгән җирле референдумда кабул ителгән карарны теркәү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә, 2018 елның 18 ноябрендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре нигезендә бирелгән сорауга:

«2019 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә 400 сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы?:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Тубэн Козгынчы торак пунктындагы Татарстан, Октябрь, К.Маркс урамына, Югары Козгынчы торак пунктындагы Тракторчылар, Тэмле Чишмэ урамына,Олыяз торак пунктындагы Тукай, Яна, С.Габдрауф урамнарына вак таш җәеп ремонтлау;
- Кыраул торак пунктында ясалма тигезсезлек урнаштыру;
- җирлек торак пунктларында җирле әһәмияттәге юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

2. Территортияне тозеклэндеруне оештыру:

- Тулбай торак пунктындагы, Тубэн Козгынчы торак пунктындагы чишмэлэргэ ремонт ясау
- Дусай торак пунктында Боек Ватан сугышында хэлэк булганнарга хэйкэл ремонтлау.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Татарстан Республикасы Мамадыш муницпаль районы Олыяз авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге 903 номерлы «Татарстан Республикасы

Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында»карарын теркәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Я.Хаев